ГЛАВА САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.02.2025 с. Сарманово № 33

«Гражданнарның язма һәм телдән мөрәҗәгатьләрен анализлауны уздыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы башлыгының 2015 елның 20 августындагы 144 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2010 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Сарман муниципаль районы уставы нигезендә, муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы прокуратурасы протестына таянып, карар иттем:

1. Сарман муниципаль районы башлыгының 2015 елның 20 августындагы 144 номерлы карары белән расланган гражданнарның язма һәм телдән мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

- 2.3 пунктта “елга ике тапкыр” сүзләреннән соң “15 көн дәвамында” сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында pravo.tatarstan.ru һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә игълан итәргә: https://sarmanovo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Сарман районы башлыгы Ф.М. Хөснуллин